ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 15 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2025, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $10^{1}$ пункт өстәргә:
«$10^{1}$) ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан раслау тәртибен билгеләү;»;

2) 4 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $9^{9}$ һәм $9^{10}$ пунктлар өстәргә:
«$9^{9}$) ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен раслау;
$9^{10}$) «Торак өлкәсендә идарә итүне үстерүгә һәм аның нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 225-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына кагылышлы белешмәләрне торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасына кертү;»;

3) 14 статьяның 1 өлешендәге беренче абзацында «шул исәптән мәдәни мирас объектларын саклауның берләштерелгән зонасын» сүзләрен «шул исәптән мәдәни мирас объектларының бердәм саклау зонасын, төзелеш һәм хуҗалык эшчәнлеген җайга салуның бердәм зонасын һәм саклана торган табигать ландшафтының бердәм зонасын (алга таба – мәдәни мирас объектларын саклауның берләштерелгән зонасын)» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының өченче абзацыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының өченче абзацы 2026 елның 1 июненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2026 ел, 25 апрель
№ 26-ТРЗ